СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
24.03.2021

г.Зеленодольск

**КАРАР**
№ 33

Зеленодольск шәһәренең 2017 елның 22 маендагы 131 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск шәһәренең муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын чыгарып төшерү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының 2017 елның 22 маендагы 131 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск шәһәре муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын чыгарып төшерү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

Хезмәт торак урыннарын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгарып төшерү өчен оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләре, һәм (яки) гражданнар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

а) хезмәт торак урыннарын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгарып төшерү турында үтенеч (гариза);

б) мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар;

в) гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар;

г) хезмәт эшчәнлеге турында кәгазьдәге (хезмәт кенәгәсе күчермәсе – оешма җитәкчесе яки кадрлар бүлеге җитәкчесе имзасы белән расланган барлык битләр, «хәзерге вакытта эшли» тамгасы куелган) яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ формасындагы мәгълүматлар (эш бирүчедә булганда);

д) торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр;

е) хезмәт торак урыныннан файдалану хокукын раслаучы документлар;

е) техник инвентарьлаштыру органыннан, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсеннән күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәү турындагы белешмәләрнең булмавы (булуы) турында хезмәткәр гаиләсенең барлык теркәлгән әгъзаларына белешмәләр;

ж) Зеленодольск шәһәрендә торакны хосусыйлаштыруда катнашмавы (катнашуы) турында хезмәткәр гаиләсенең теркәлгән барлык әгъзаларына, 1991 елның 01 июленнән соң хезмәт торагында теркәлгән очракта, тууга бәйле рәвештә гражданнарны теркәүдән тыш, «Зеленодольск муниципаль районының ТКХ департаменты» МБУ белешмәләре;

з) йортны яшәү өчен яраксыз дип таныган очракта (авария хәлендә), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ведомствоара комиссиясенең йортны яшәү өчен яраксыз (авария хәлендә) дип тану турында бәяләмәсе.

« а » - « г » пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырыла.

« д » - « з » пунктчаларында күрсәтелгән документларны, гражданнар үз инициативасы белән бирмәгән булса, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, күрсәтелгән документларга ия булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан, законнар нигезендә соратып алына.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Мәэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**